## Булатова М.Р. Курмантауский говор среднего диалекта татарского языка в этнолингвистическом аспекте

Китап сөючеләрнең киштәсендә тагын бер китап урын алды. Ул татар тел белеменең кызыклы да, әһәмиятле дә булган тармагына – диалектологиягә багышланган һәм «Курмантауский говор среднего диалекта татарского языка (в этнолингвистическом аспекте)» (Казань: Издательство Магариф – Вакыт, 2016) дип атала. Китапның авторы филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының фәнни хезмәткәре Миңнира Рәхим кызы Булатова.

Башкортстанның көньягында татар теленең сөйләшләре әле һаман ачыла тора, өйрәнелә килә. Менә шуларның берсе – кормантау сөйләше. Бу сөйләш М.Р. Булатова тарафыннан ачыла һәм авторның 2011–2015 елгы фәнни экспедицияләре ярдәмендә баетыла.

Китапта бик әһәмиятле кереш бирелгән, анда бу территориядә таралган сөйләшләр турында кыскача мәгълүмат китерелә: тепекәй (Д.Б. Рамазанова), турбаслы (Ф.С. Баязитова) һәм башкалар (И.С. Насипов).

Автор үзеннән алда бу өлкәне тикшереп өйрәнүчеләр хезмәтенә зур игътибар бирә, кормантау сөйләшен шулар белән чагыштырып өйрәнүгә зур көч куя. Аннан соң әлеге сөйләшне Башкортстанның көнбатыш, төньяк, үзәк өлешләрендә таралган сөйләшләр белән җентекләп чагыштырып, аерымлыкларын берәмтекләп ачыклап күрсәтә бара. Башка татар сөйләшләре һәм төрки телләр белән дә чагыштырулар уздыра.

Хезмәтнең тагын бер әһәмиятле якларыннан берсе шунда: автор сөйләшнең формалашу тарихына зур урын бирә, архив материалларын иркен файдалана, диалектологларның, археологларның, тарихчыларның хезмәтләрен тирәннән чагыштырып, тикшереп өйрәнә (Н.В. Никольский, С.И. Руденко, А.Н. Усманов, А.П. Смирнов, А.Х. Халиков, Р.Г. Кузеев, В.Ф. Генинг, Н.А. Мәҗитов, М.З. Зәкиев, Л.Т. Мәхмүтова, Ф.Г. Гарипова, Д.Б. Рамазанова, А.З. Әсфәндияров, И.С. Насипов һ.б.). Хезмәткә көчле тарихилык хас: бер яктан, анда кормантау сөйләше вәкилләренең тарихы яктыртыла, икенче яктан, сөйләшнең тарихы чагыла һәм глоттогенез һәм этногенез мәсьәләләре үзара бәйләнештә сурәтләнә.

Кормантау сөйләше Башкортстанның Гафури районы Кормантау, Бурлы, Яңа Бурлы (Новые Бурлы), Җилем-Каран (Зилим-Каран), Таштамак / Абдулла (Абдуллино), Кызыл-Яр авылларында таралган. М.Р. Булатова халык арасында йөргән легендалар, архив материаллары, ревизия кенәгәләре нигезендә һәрбер авыл тарихын, тормышкөнкүрешен тәфсилләп яза.

Хезмәттә тел белеменең бөтен тармаклары буенча анализ

ясала. Башта фонетик үзенчәлекләр бүлегенә күз салыйк. Автор *и~ә, ә~и* (*кәштә* – әд. киштә, *кәбән* – кибән, *әпәй* – ипи) кебек татар сөйләшләренең киң таралган күренешләре белән беррәттән, *о~у* (*олай* – әд. улый, *боғаз* – бугаз), *ө~ү* (*көзәтү* – әд. күзәтү), *у~ы* (*қарлуғач* – әд. карлыгач), *ү~и* (*күгәwен* – әд. кигәвен) кебек телнең аеруча борынгы катламнарына барып җитә торган үзенчәлекләрне тота алган һәм аларның характерын тел материаллары белән аңлатуга, башка сөйләшләр белән чагыштыруга зур урын бирә.

Сөйләшнең сузык һәм тартык авазлар системасы автор тарафыннан тулы һәм бай мәгълүматлы итеп аңлатыла. Сузыкларның, дифтонгларның составы (*-ай/-әй, -ый/-ый*) белән дә сөйләш, бер яктан, Урал төбәге татар сөйләшләренә якын торса, икенче яктан, аның Касыйм, Чүпрәле, Пермь, Себер татарлары кебек борынгы сөйләшләр белән зур уртаклыгы да ачыла.

Күпчелек тартык авазларның әйтелеше һәм кулланылышы буенча кормантау сөйләше әдәби телдәгечә. Шуның белән бергә аерымлыклар да бар. Автор нечкә әйтелешле сүзләрдә ***ш*** авазының әйтелешен аерып чыга: *щәл / ш'әл* – шәл, *бищ* – биш һ.б. Мондый күренеш урта диалектның златоуст һәм көнчыгыш диалектның саз ягы сөйләшләрендә дә бар.

Көньяк Башкортстандагы сөйләшләр өчен ***ч*** авазының кулланылышы катлаулы мәсьәлә булып тора. Татар-башкорт контактлы сөйләшләрендә аның кулланылышы төрлечә. Златоуст сөйләшендәге ***с*** *ц*-лаштыручы мишәрләргә кайтып кала дип санала. Тепекәй сөйләшендә – башкорт теле йогынтысы дип карала, учалы сөйләшендәге *(ч>)с* шулай ук мишәрләрдән булырга мөмкин. Кормантау сөйләшендәге *(ч>)с* шулай ук *ч*-ләштерүче мишәрләрдән килә булса кирәк.

Көньяк Башкортстандагы сөйләшләр өчен ***ч*** авазы урынына ***с*** куллану характерлы үзенчәлекләрнең берсе булып тора. Тепекәй, учалы, кормантау һәм златоуст сөйләшләре әлеге күренеш буенча берләшәләр. Гомумән, автор үзенчәлекләрне билгеләүгә, аңлатуга объектив якын килә, башка сөйләшләрдәге күренешләрне истә тотып аңлата белә. Бу яктан авторның китап азагында урнаштырылган (348–349 битләр) таблицасы бик урынлы.

Китапның ачышы булып саналган үзенчәлекләрдән тагын **г**$^{г}$ авазын күрсәтергә кирәк. **Г**$^{г}$ (мәсәлән, *Г*$^{г}$*өлназ* – әд. Гөлназ) дип тамгалана торган бу вариант урта һәм көнбатыш диалектларының үзара тәэсир итешүе нәтиҗәсендә барлыкка килгәннәр.

Хезмәттә, гомумән, фонетик яктан бик нечкә күзәтүләр, авазлар кулланылышында күптөрле үзенчәлекләр чагылган, фонетист булырга теләүчеләр өчен бик бай материал бирелгән.

Шундый ук кызыклы да, бай да бүлек итеп «Морфология» бүлеген дә санарга мөмкин. Биредә барлык сүз төркемнәре состав ягыннан да, функцияләре буенча да тирән өйрәнелгәннәр. Сүз төркемнәре әдәби тел белән

чагыштырма планда тикшереләләр. Һәр сүз төркеменең категорияләре аерым карала һәм һәрберсенең аермалы якларын күрсәтүгә зур урын бирелә.

Мәсәлән, исем сүз төркемен генә алыйк. Билгеле булганча, иркәләү-кечерәйтү функциясе исемнәрнең аерым күрсәткече булып тора һәм ул *-кай/-кәй, -чык/-чек* кушымчасы белән белдерелә. М.Р. Булатова исә кормантау сөйләшендә *-кай/-кәй* кушымчасының 8 функциясен билгели һәм аларның һәрберсен тәфсилле итеп анализлап чыга: иркәләү-кечерәйтү мәгънәсеннән тыш, кеше исемнәре һәм туганлык терминнарына гына түгел, йорт хайваннары, җансыз һәм абстракт предмет белдергән исемнәргә дә ялгануы (*бәрәскәй, хәтеркәй*), ясагыч кушымча булуы (*сәпәкәй итү* – әд. кул чабу, *сәнсәкәй бармак*), сорау алмашлыгына да кушылуы (*нәмәкәй, нәрсәкәй*) һ.б. Күплек кушымчасының экспрессив, эмоциональ берничәшәр мәгънә төсмерләрен, килешләрнең функцияләрендә берничәшәр мәгънә функцияләрен ача. Шулай итеп, М.Р. Булатова һәр сүз төркеме турындагы өйрәтмәләрне баета.

Шундый ук юл белән башка сүз төркемнәре дә анализлана: сыйфат ясагыч кушымчалар, сан ясагыч кушымчалар *-лаган/-ләгән* (*йегермеләгән бала* – әд. егермеләп), төп сан урынына җыю санын куллану (*икәүсе уқый* – әд. икесе укый), алмашлыклар: *анау, монау, нәмә, қайсылай, әләйди* (әллә нинди), *берәй* һ.б.

Алмашлыкларның төрләнешендәге аерымлыклар исә борынгы төрки телгә үк барып тоташа: *безең, менің* һ.б. Юнәлеш килешендә фонетик вариантлар хас (мәсәлән: *мийә/мийа/миңә* һ.б.). Шундый ук формалар бәрәңге, дөбъяз, керәшен, пермь һәм башка татар сөйләшләрендә, башкорт, ногай, караим, азәрбайҗан һ.б. телләрдә күзәтелә.

Татар телендә диалекталь күренешләргә иң бай сүз төркеме булып фигыль санала. М.Р. Булатованың тикшеренүләре дә шуны күрсәтә. Һәр заман формасы, аның төрләнеше, функцияләре автор тарафыннан бик җентекләп анализлана: затланышлы, затланышсыз формалар, инфинитив формалары *-ырга/-ергә, -мага/-мәгә, -мак/-мәк, -уга/-үгә, -асы/-әсе.*

Ярдәмлек сүз төркемнәре дә кормантау сөйләшендә шактый үзенчәлекле икәне ачыклана. Автор аларның составы ягыннан да, функцияләре ягыннан да өйрәнә торган сөйләштә кызыклы үзенчәлекләр таба алган.

Кайбер бәйлекләргә вариантлылык хас: *кебек / күwек / кеwек / күк; сыман / сымақ; белән / белә / была; тикле / тиклек / тиклем; қадәр / қәдәр / хәдәр(е) / хәдәрле* һ.б. Сөйләш өчен үзенчәлекле бәйлекләр дә табылган, алар татар теленең мөмкинлекләрен чагылдыра: *алта* – әд. алып. Гомумән, *ал* – тамырыннан мондый бәйлекләр Урал тирәсе сөйләшләрендә күп очрый. Мәсәлән: *ала, әләп* – әд. алып һ.б. Сөйләштә бәйлек сүзләр дә шактый. Әдәби телдәгеләрдән тыш, сөйләштә *тапкыр, кыр, эргә* һ.б. кулланыла.

Теркәгечләр һәм кисәкчәләр бүлекчәләре дә автор тарафыннан

җентекләп, иренмичә анализланганнар, мисаллар күп китерелә.

Хезмәтнең уңышлы яклarыннан берсе – анда синтаксис бүлеге аерым бирелә, синтаксик категорияләр махсус тикшерелә, моның өчен диалектология фәнендә синтаксис белән бәйле мәсьәләләрнең куелышы, диалекталь синтаксисның өйрәнелеше турында кереш урнаштырыла. Синтаксис мәсьәләләре сүзтезмәләр, хәбәрне формалаштыру, хикәя җөмләнең төзелеше турында, өндәү җөмләләрнең бирелеше, инверсия, кушма җөмләләрнең типлары дигән бүлекчәләрдә яктыртыла, кайбер мәсьәләләр яңалыклы булуы белән үзенчәлекле.

Автор кормантау сөйләшенең лексик үзенчәлекләренә дә зур игътибар бирә. Диалекталь лексиканы тематик төркемнәргә бүлеп тикшерә. Бер төркем сүзләр сөйләштә икенче мәгънә төсмере дә белдерә икән: *бәс* – 1) сыкы, 2) көрән төс (коричневый); *җай* – 1) тәртип, тыныч, мөмкинлек, 2) әкрен, иплэп; *азаҡ* – 1) әд. азак, 2) аннары һ.б. Кайбер сүзләр үзенчәлекле төсмер белдерә: *ҡыстырма* – кер кыстыргычы, *бер килке* – бервакыт һ.б.

Хезмәттә кантуганлык һәм никах туганлыгы атамалары тулысынча, система итеп яктыртылган: *әни, әти, энекәш, апа, ага, түтәй, бисә/бичә, каембикә, балдыз* һ.б.

Кеше белән бәйле атамалар шулай ук үзенчәлекле төркемне тәшкил итәләр: *йаwрын* – әд. иңбаш; *йөнтәфи* – йонлач; *көмәгәй* – аңкау; *танау* – борын; *тубыҡ* – тез; *сыйҡан* – чуан; *әшимә* – әкрен эшләүче, җыйнаксыз (кеше); *бүсмәт* – 1) юан, 2) әкрен кыймылдаучы; *ҡапаҡ* – кукраючан; *саха* – сантый; *мыҡтым* – нык, таза; *шаҡару* – каеру һ.б.

Үсемлекләр, хайваннар дөньясы белән бәйле лексика шулай ук бик бай: *оргасы* – саулык/теше; *драж* – төклетура; *ҡайау* – корт угы; *өкө* – мәче башлы ябалак; *йыла* – элмә; *ҡарга ҡарагаты* – карга шомырты; *кәшәнәк* – касә яфрагы; *көрән мәтрүшкә* – мәтрүшкә; *песәй күмәсе* – песи борчагы; *тал көсөге* – тал песие; *кәшәнәк* – касә яфракчыгы; *сасҡау* – дымлы, томанлы (һава) һ.б.

Матди мәдәният белән бәйле лексика да бик бай, анда төп сүзләрдән башка, үзенчәлекле вариантлар да күп күзәтелә. Кайберләрен күрсәтеп үтик: *кәлкүн* – әд. таган, *төнәү* – кунача, *җилпүгес* – йолпыч, *пежник* – сукыр лампа, *чиҡалай* – мүкләгеч, *башантай* – йон оекбаш, *кәзә тойаҡ сабата* – күтәртмәле чабата һ.б.

Сөйләштә рухи мәдәният белән бәйле үзенчәлекле атамалар системасы формалашкан: *аулаҡ өй, сәмриҡош уйыны, сабан сөрөш, үсмә алыш уйыны* һ.б. Кайбер бәйрәм исемнәре игътибарга лаек: *ҡарга ботҡасы, җизнәй бүләге, сугым өмәсе, җәй ташы* һ.б. Бу төр лексика автор тарафыннан кушымта итеп бирелгән.

Лексика бүлегендә генетик катламнар да берникадәр аерып чыгарыла: гарәп-фарсы, рус, башкорт, фин-угыр алынмалары.

Сөйләш диалектизмнарга бик бай, аларның кайберләре әле өйрәнелеп кенә килә. Автор туган ягы сөйләшен яхшы белә, бай материал тәкъдим итә. Китерелгән лексик материалларның бер өлеше фәнгә беренче башлап кертелә.

Кормантау сөйләшенең фонетик, грамматик, лексик үзенчәлекләрен һәм бу сөйләш вәкилләренә хас булган гореф-гадәтләрне, йолаларны, халык авыз иҗатын, авыллар тарихын һәм тормыш-көнкүрешен чагылдырган материаллар сөйләү үрнәкләре рәвешендә кушымта бүлегендә бирелә.

Гомумән, Миңнира Булатованың монографиясе татар диалектологиясен үстерүгә зур өлеш кертә. Хезмәтнең кайсы бүлегенә күз салсак та, авторның яңалыклары шактый, кормантау сөйләше әдәби телгә дә яңалыклар кертә. Хезмәт татар диалектологиясенең казанышларын истә тотып язылган, югары дәрәҗәдәге анализ үрнәге итеп карала ала.

***Рамазанова Дария Бәйрәм кызы**,*
*филология фәннәре докторы, профессор*